СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 г.Зеленодольск № 299

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен 1- 6 нчы кушымталарда каралганча кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Зеленодольск муниципаль районының 1 нче - 6 нчы кушымталарында күрсәтелгән шәһәр һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары хисабына гамәлгә ашырыла, шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зеленодольск муниципаль районы Советы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә

өстәмә рәвештә үз матди ресурсларын һәм финанс чараларын кулланырга хокуклы.

4. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**

1 нче кушымта
2023 елның 20 июленнән
299 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы
Советы
карарына

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге үзенең вәкаләтләренең түбәндәге өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

Панау авылындагы авылындагы Никольск чиркәвенә килү юлын каплауның күчеш тибын төзүне.

2 нче кушымта
2023 елның 20 июлендәге
299 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы
Советы карарына

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшыра:**

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге вәкаләтләренең бер өлешен.

3 нче  кушымта
2023 елның 20 июлендәге
299 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы
Советы карарына

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге өлешен тапшыра:**

- чокырларны ремонтлауны;
- Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында тротуар төзүне.

4 нче кушымта
2023 елның 20 июлендәге
299 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы
Советы карарына

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге өлешен тапшыра:**

- Әйшә авылындагы чокырларны ремонтлауны;
- Әйшә авылында килү юлын каплауның күчеш тибын төзүне.

5 нче кушымта
2023 елның 20 июлендәге
299 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы
Советы карарына

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге өлешен тапшыра:**

- юлларда чокырларны ремонтлауны;
- Осиново авылында керү кесәләрен(заездных карманов) урнаштыруны;
- Осиново авылында тротуарлар участогын төзүне;

6 нчы кушымта
2023 елның 20 июлендәге
299 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы
Советы карарына

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Новопольский» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшыра:**

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге вәкаләтләренең бер өлешен.